2026 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Ямаш авылы җирлеге Ямаш авылында гражданнарның үзара салымын кертү турында

## ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

28 ноябрь 2025 ел № 8

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45,69 статьялары нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Ямаш авыл җирлегенең Ямаш авылында гражданнар җыены карар кабул итте:

1. 2026 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Ямаш авыл җирлегенең Ямаш авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм даими яшәүче һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертергә, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан, махсус хәрби операциядә катнашуга бәйле рәвештә хәрби хезмәт узу турында контракт төзегән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә: су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны һәм халыкка су бирүне (су белән тәэмин итү линиясен алмаштыруны) тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау; торак пункт территориясен төзекләндерү; урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформаторларны һәм башка подстанцияләрне ремонтлау һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элементләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны (урамнарны яктырту фонарьлары сатып алу һәм урнаштыру)?»

3. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Ямаш авылы, Советская урамы,109А йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм кабул ителгәннән соң 10 кен эчендә Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Ямаш авыл җирлеге башлыгы Е.С.Ларин